ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.04.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1144**

2026 елга Зеленодольск шәһәрендә салым салынырга тиешле һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2026 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2026 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2025 елның 08 декабрендәге 777/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен 2026 елга Зеленодольск шәһәрендә салым салынырга тиешле һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының максималь күләмен түбәндәгечә расларга:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 105 075,32 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 105 075,32 сум;

1.1.3. өч кешедән һәм аннан күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 105 075,32 сум;

1.2. Салым салынырга тиешле булган гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәтк хакының максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 2 756 628,00 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 5 513 256,00 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 8 269 884,00 сум;

1.2.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 11 026 512,00 сум;

1.2.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 13 783 140,00 сум;

1.2.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 16 539 768,00 сум;

1.2.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 19 296 396,00 сум

2. «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип танымганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

**2026 елга**
**салым салынырга тиешле һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. **Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече**

   **СЖ = НП*РС*РЦ, биредә**

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасына карап торак урын сатып алуның базар хакы исәп-хисап күрсәткече;
НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - Зеленодольск шәһәрендәге торак урыннарының 1 кв. м.уртача күрсәткеченә туры килә торган торак урынның бер квадрат метры мәйданының уртача исәпләнгән базар бәясе (2026 ел башына – 153 146,0 сум).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
    СЖ = 153 146*18*1 = 2 756 628
б) ике кешедән торган гаилә өчен:
    СЖ = 153 146*18*2 = 5 513 256
в) өч кешедән торган гаилә өчен:
    СЖ = 153 146*18*3 = 8 269 884
г) дүрт кешедән торган гаилә өчен:
    СЖ = 153 146*18*4 = 11 026 512
д) биш кешедән торган гаилә өчен:
    СЖ = 153 146*18*5 = 13 783 140
ж) алты кешедән торган гаилә өчен:
    СЖ = 153 146*18*6 = 16 539 768
з) җиде кешедән торган гаилә өчен:
    СЖ = 153 146*18*7 = 19 296 396

2. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ ПС / $(1+ПС)^{-КП}$/(0,25*РС), биредә**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасына карап торак урын сатып алуның базар хакы исәп-хисап күрсәткече;
ПС – кредит буенча айлык процент ставкасы (16% / 12);
КП -кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);
РС-гаилә әгъзалары саны;
0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;
0,25 — гаиләнең гомуми айлык кереме белән кредит буенча түләү нисбәте

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

$$ПД = 0,7*2\ 756\ 628*0,013 / (1-(1+0,013)^{-240}) / (0,25*1) = 105\ 075,32$$

б) ике кешедән торган гаилә өчен:

$$ПД = 0,7*5\ 513\ 256*0,013 / (1-(1+0,013)^{-240}) / (0,25*2) = 105\ 075,32$$

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

$$ПД = 0,7*8\ 269\ 884*0,013 / (1-(1+0,013)^{-240}) / (0,25*3) = 105\ 075,32$$

г) дүрт һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

$$ПД = 0,7*11\ 026\ 512*0,013 / (1-(1+0,013)^{-240}) / (0,25*4) = 105\ 075,32$$